Минзәлә гимназиясе укучылары газетасы

# ЯШЬЛЕК

Октябрь 2025

**Бу санда:**

**2-3 бит – Өлкәннәр көне**

**4-5 бит - Укытучылар көне**

**6 бит – “Яңа шәхес” рубрикасы**

**7-8 бит – гимназия яңалыклары**

**9 бит - котлыйбыз**

***Кайгырганда юатучы,***
***Безнең өчен ут йотучы.***
***Гаделлеккә өйрәтүче,***
***Рәхмәт сиңа, Укытучым!***

***Чәчләреңә бәсләр кунган.***
***Гүя ап-ак кышкы урман.***
***Гомер буе без бурычлы,***
***Рәхмәт сиңа, Укытучым!***

***Өермәдәй уй булгандыр.***
***Күзләреңә яшь тулгандыр.***
***Озатканда унынчыңны,***
***Рәхмәт сиңа, Укытучым!***





Төбәк “Сәләт” клублары өчен XXII гамәли уку-укыту семинары кысаларында узган “Күргәзмә” конкурсында җиңү яулап, “Сәләт-Минзәлә” клубы Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министрлыгы, “Сәләт” яшьләр иҗтимагый фонды һәм Сәләт яшьләр үзәгенең дипломы белән бүләкләнде.



“Сабантуй” журналы хезмәткәрләре бездә кунакта. Очрашу турында тулырак газетабызның 7нче битеннән укыгыз.



# Өлкәннәр көне

***Укучылар үзләренең әби-бабайларын, дәү әниләрен бәйрәм белән котладылар*.**

Кадерле дәү әнием! Сине өлкәннәр көне белән котлыйм. Сиңа шатлык, сәламәтлек, бәхет телим. Безне гел үз елмаюың белән шатландырып торасыз, тәмле ризыклар белән сыйлыйсың. Аның өчен без бик рәхмәтле. Күптән күрешкәнебез юк. Бу елларда кунакка килермен. *Оныгың Алинә*

---

Кадерле, әбием! Бүген 1 нче октябрь – өлкәннәр көне. Бу хатны сине котлар өчен язам. Әбием, сиңа саулык-сәламәтлек, озын гомер телим. Минем хәлләрем әйбәт. Иртәннән кичкә кадәр укыйм, имтиханнар бирәсем бар. *Оныгың Рөстәм.*

---

Хәерле иртә, Гүзәлия әбекәй! Бабыкай белән икегезне дә өлкәннәр көне белән котлыйм. Сезгә бик нык сәламәтлек, шулай ук шатлык, гаилә бәхете телим. Бабыкай белән бергә күп-күп еллар бергә яшәргә язсын! Бергә булыйк, бердәм булыйк! Без сезне бик яратабыз. Әни көн саен эштә. Әти дә эшкә киткәч, авылга да кайтып булмый, вакыт та җитми. Эх, кайтасы иде хәзер авылга сезнең янга!!! *Оныгың Рияз*

---

Исәнме, абзыкай! Сезне өлкәннәр көне белән котлыйм. Сезгә саулык-сәламәтлек, озын гомер, бәхет, шатлык телим. Хәлләрегез ничек? Безнең, аллага шөкер, әйбәт. Син әйткәнчә, “5” легә укыйм, зарядканы көн саен ясыйм. Имтиханнарга ныклап әзерләнәм. *Оныгың Инсаф.*

---

Исәнме, әбием! Сине өлкәннәр көне белән котлыйм. Сиңа бәхет, шатлык, озын гомер телим. Сиңа инде 76 яшь. Аңа да карамастан син әле яшь кебек. Күзләрең дә балаларныкы кебек янып тора. Киләчәктә дә шундый булып кал, әбием! Мин сине бик-бик яратам. *Оныгың Илдан.*

---




Кадерлеләрем! Бу якты бәйрәмдә сезне котлыйсым килә. Киңәшләрегез, кайгыртучанлыгыгыз һәм мәхәббәтегез өчен рәхмәт белдерәсем килә. Сез - безнең иң кадерле кешеләр һәм без сезнең безнең өчен эшләгәннәрегезнең кадерен беләбез. Сезгә һәрвакыт ныклы сәламәтлек, шатлык һәм бәхет телим. Сезнең көннәр җылы, елмаюлы һәм күңелле мизгелләр белән тулы булсын. Без сезгә мәхәбәтебезне һәм игътибарыгызны бүләк итү өчен һәрвакыт янәшә булачакбыз. *Оныгың Софья*

---

Минем яраткан һәм кадерле әбием һәм бабам! Сезне өлкәннәр көне белән котлыйм. Беренче чиратта сәламәтлек телим, чөнки сезнең яшьтә ул иң кирәк әйбер. Ләкин картаям дип уйламагыз, сездән ярдәм кирәк чаклар була. Әле дә сез бар үрнәк алырлык. Озын гомер, якты тыныч тормыш-минем сезгә әйтер теләкләр. Рәхмәт әйтәм сезгә чын йөрәктән, сезнең гомер – безнең горурлык. *Оныгыгыз Ралина.*

---

Хөрмәтле әбием! Мин сине өлкәннәр көне белән котлыйм. Син инде өлкән яшьтә булсаң да, бик актив тормыш алып барасың. Өйгә керү белән тәмле бәлеш исе килә. Ял көннәре синең белән күңелле уза: малларга ашарга бирәбез, бакчада бергәләп эшлибез һәм кичен капка төбендә үрдәкләр саклыйбыз. Ә шәһәргә китү белән синең тәмле коймагын сагындыра. Әбием! Сиңа ныклы сәламәтлек, исәнлек- саулык телим.

Күп еллар яшәргә насыйп итсен, әбием. Сине бик-бик яратып *оныгың Салават.*

---

Әбиемнәр һәм бабам! Сезне чын күңелдән өлкәннәр көне белән котлыйм. Еллар үтеп барса да, сәламәтлегегез кимемәсен, һаман да яшь күңелләрегез нур сибеп торсын, кояш кебек балкып торсын. Тормышлар матур мизгелләр белән тулсын. Өлкән яшьтә дә хыялны тормышка ашырырга вакыт бар. Шуңа күрә хыялыгызга көчегез җитеп торсын. Өлкәннәр көне белән сезне, олы яшьтәге апа-абыйлар! Йөзләрдә җыерчыклар күренсә дә, күңелләр гел яшь булсын!Сезне яратып *оныгыгыз Камилә*

---

### Алтын вакыт

"Кешеләрнең күңелләре кайчан нур сибә башлый микән?",- дип беркөнне сорау бирдем үземә. Уйлый торгач вакыт үтте, сентябрь дә якынлашты. Психология белгечләре кешенең күңел халәте ел фасылларының үзгәрүе белән бәйле диләр. Чыннан да бер үк кешенең дөняга карашлары ел дәверендә берникадәр үзгәрә: җәй ул үзен иректә хис итә, кыш көне ул якын кешеләр белән бергә булырга тели, ә язын бертуктаусыз эшли. Бу күренеш миңа шулай күз алдыма килә. Бәлки башкалар икенче төрле уйлыйдыр. Әмма алтын вакыт кайчан килеп җитә?

Сентябрь ае миңа сер ачты; кешенең бер вакытта җаны тыныч булуы, эшне дә төгәл эшләве, туганнары белән элемтәдә булуы – шушы алтын вакытның килеп җитүен аңлата да инде. Ул вакыт яфраклар сары,

кызыл булуы белән бәйле икән. Тагын урманнарның балкып торулары белән, хуш исләр килеп торганда "көз житте" дип уйлап кую белән бәйле. Нәкъ менә көзнең матурлыгын кешенең күңелендә шундый ук матурлык тудыра. Аның "яфрак бураны" күңелдән авырлык төшкән сыман тоела. Табигать көз көне генә үзенең иң тымсымлы күлмәкләрен, йолт-йолт килгән бизәкләрен, нурлы кояшын күрсәтә. Минем өчен көз-ул шулай ук яңа старт алу, яңа үрләргә тартылу, хыялымны чынга ашыру. Көз - ул гармония, көз - ул алтын вакыт!

*Камилә Галиева*

## *Укытучылар көне*

***Укытучы һөнәре - җир йөзендә иң изге һөнәрләрнең берсе. Һәр кеше моның мәгънәсенә төшенә. Укытучы бөтен көчен биреп балаларга аң - белем, тәрбия бирергә тырыша. Нәкъ менә сез - укытучылар, тәрбиячеләр, балаларда мөстәкыйльлек, жаваплылык, илебезнең матур киләчәге өчен иҗади хезмәт итүче шәхесләр тәрбиялисез. Сезнең фидакарь хезмәтегез, югары һөнәри осталыгыз, сабыр һәм ярдәмчел булуыгыз өчен тирән ихтирамыбызны белдерәбез. Гасыр белән бергә атлап барырдай, заманга лаеклы алмаш тәрбияләүдә сез искиткеч җаваплы, олы эш алып барасыз. Тынгысыз һәм катлаулы, әмма изге һәм абруйлы хезмәтегездә уңышлар гына юлдаш булсын.***

***Без, барлык мәктәп укучылары, сезне профессиональ бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез. Сезгә исәнлек-саулык, озын гомер, җан тынычлыгы телибез. Изге эшләрегез безнең өчен, балалар өчен. Шул башкарган хезмәтегездә иминлек телибез сезгә. Үзегезнең тырышлык нәтиҗәсен укучыларыгызның өченче меңьеллыкның тулы хуҗалары булып, төрле өлкәләрдә уңышлы хезмәт куюларын күреп горурланырга насыйп булсын. Тагын бер кат бәйрәм белән сезне, хөрмәтле укытучыларыбыз!***

Мин Минзәлә шәһәренең гимназиясендә алтынчы ел белем алам. Безгә укырга иң мөһим кешеләр - укытучылар ярдәм итә. Һәрбер укытучы да үз хезмәтен, укучыларын яратып эшли. Миңа барлык

укытучылар да ошый. Әмма физкультура дәресен бигрәк тә яратам. Безнең укытучыбыз - Ленар Нурович. Башлангыч сыйныфтан бирле ул дәресләрне күңелле, ә иң мөһиме файдалы итеп үткәрә. Ленар Нурович безне төрле ярышлар, саф һавада уеннар белән спортка гашыйк итте. Физкультура сәламәтлегебез, бәхетле киләчәгебез өчен бик мөһим бит. Мин мәктәптән тыш чаңгыда шуарга яратам. Ленар Нуровичның монда зур өлеше бар. *Укучыгыз: Набиуллина Афина.*

--------------------------------

Мәктәптә укытучысыз берничек тә булмый. Һәр көнне укытучы үз дәресен укыта. Мәктәптә нинди генә дәресләр юк: күбрәк рус, татар телләре укытыла. Сирәк кенә инглиз теле дә була әле. Ләкин чит тел булгач, ул безнең өчен бик катлаулы. Шулай да миңа инглиз теле ошый. Аны Гүзәл Флүр кызы укыта. Ул дәресләрне бик кызыклы итеп, гел инглиз телендә генә алып бара. Безнең дә бу телне шулай камил беләсебез килә. *Язгөл Галиева.*

---------------------------------

Минем беренче һәм яраткан укытучым – ул Раушания Шамил кызы. Аңа карата минем хөрмәтем чиксез. Раушания апа безгә әниләрдәй күңел җылысын биреп, укырга, язарга өйрәтте. Игътибарлы, ихтирамлы, кече күңелле булу серләренә төшендерде. Сыйныфтагы барлык балаларны бергә туплады. Башлангыч сыйныфны тәмамлап, бүгенге көндә дә без, сыйныфташларыбыз белән, бер гаиләдәй дус, тату яшибез. Безнең татулыгыбыз да беренче укытучыбызның тырышлыгы. *Халиуллина Аида.*

Минем яраткан укытучым - Ольга Сергеевна. Ул - безнең рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Рус теле – күп халыкларны берләштерә һәм дуслаштыра торган, бик бай һәм матур тел. Рус телендә танылган шагыйрь һәм язучылар: Пушкин, Лермонтов, Есенин, Гоголь, Толстой һәм башкалар матур-матур әсәрләр иҗат иткәннәр. Шушы камил телгә безне Ольга Сергеевна өйрәтә. Аның дәресләре бик кызыклы, эчтәлекле. Ольга Сергеевна рус телен бик яхшы итеп өйрәткәнгә күрә бишенче сыйныфта Россиякүләм тикшерү эшләрен мин бишле билгесенә эшләдем. Укытучыбыз сау-сәламәт булып, озак еллар эшләсен. *Әхмәтова Ләйлә.*

--------------------------------------

Безнең мәктәптә яхшы, игелекле һәм үз һөнәренә тугры булган укытучылар күп. Ләкин бер укытучыны аеруча яратам. Ул – Лилия Владимировна - биология һәм география фәннәрен укыта. Ни өчен соң миңа аның дәресләре ошый? Лилия Владимировна укыта торган иң яраткан дәресем – биология. Анда мин мавыктыргыч мәгълүмат алу гына түгел, ә белемнәремне практикада да куллануга ирештем. Дәрестә без тере организмнарның төелешен, бактерияләрне, вирусларны һәм башкаларны өйрәнәбез. Миңа Лилия Владимировна үзенең гадел һәм игелекле булуы белән ошый. Рәхмәт сиңа, укытучым! *Нурмөхәмәтова Мәликә.*

**Безнең илдә кеше бәяләп бетерә алмаслык кыйммәтле хәзинә. Кешеләр-илнең хуҗасы һәм тоткасы. Ә илебез киләчәгенең тоткасы сезнең кулларда, хөрмәтле укытучыларыбыз! Сез кешеләргә белем ачкычы бирәсез, кешеләрне кеше итәсез, олы юлга илтәсез. Сезгә барысы өчен олы рәхмәтебезне белдерәбез!**

**“Япь-яшь чаклар, матур чаклар бар иде” дип аталган фотоконкурс игълан итәбез. Укытучыларыбызның бала чактагы, яшьлек фотоларына карап, аларны танучылар булыр микән?**

# Фотоконкурс















# “Яңа шәхес”



**Кыскача мәгълүмат:**
**Исеме: Хамматова Гүзәлия Габделәхәт кызы**
**Туган көне: 31 нче декабрь**
**Шөгыльләре: бәйләргә, бакча эшләре белән шөгыльләнергә яратам.**
**Яраткан ризыклары: татар халкының милли ризыкларын пешерергә яратам. Иң яраткан ризыгым - гөбәдия**
**Яраткан фильмы: төрек сериаллары.**

- **Сез нинди уку йортын тәмамладыгыз?**
  Минзәлә педагогия училищесында 4 ел укыдым. Читтән торып Алабуга дәүләт педагогия университетын тәмамладым. Белгечлегем буенча мин - татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
- **Гимназиягә эшкә килгәнче сез кайда эшләдегез?**
  2008 нче елда Минзәлә кадет мәктәбе ачылды. Шул вакыттан бирле мин анда татар теле һәм әдәбияты фәнен укыттым. Эшемне бик яратып башкардым. Шигърият яратучылар өчен “Шигъри тәлгәшләр” һәм журналистика түгәрәкләрен алып бардым. Укучылар белән берлектә “Юный кадет” исемле газета чыгардык. 2025 нче елны, лаеклы ялга чыгу сәбәпле, эштән киттем.
- **Кадетлар мәктәбе белән шәһәр мәктәпләрендә аерма бармы?**
  Аерма бар һәм булырга да тиеш инде. Кадетлар мәктәбендә уку планына кергән төп дәресләрдән башка, көн саен өстәмә дәресләр каралган. Дәресләр кичке 6 га кадәр дәвам итә һәм балалар һәр көнне 10 дәрес укыйлар. Кадетлар мәктәбен тәмамлаган балалар хәрби уку йортларына укырга керергә тиешләр. Шуңа күрә, балаларның сәламәтлеге дә зур роль уйный. Һәр көн зарядка ясаудан, линейкадан башлана. Көн саен стройда йөрү осталыгы дәресләре, тактика, туризм, автомат сүтеп җыю серләрен өйрәнү дәресләре программага кертелгән.
- **Буш вакытыгызда нәрсәләр белән шөгыльләнәсез?**
  Укытучы кешегә һәрвакыт вакыт җитми инде.... Шулай да, буш вакыт булганда, тәмле ризыклар пешереп, балаларымны-оныкларымны сыйларга яратам. Минем 5 оныгым бар. Бик зур булмаса да, яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәкләр үстерергә бакчам бар. Бакчамда үскән җимешләрдән как ясап, якыннарымны - туганнарымны сыйлыйм. Бакча эшләреннән бушаган вакытта, “илһам” килгәндә, шигырьләр язарга яратам. Бүгенге көндә 60-65 ләп язылган шигырем бар. Шунысы куанычлы: туган авылым Әтрәклегә багышлап язган шигыремә атказанган композитор Зиннур Сафиуллин көй иҗат итте. Һәм ул җыр авылым бәйрәмнәрендә яңгырый.
- **Сез үзегезнең иҗат җимешләрегезне китап итеп бастырып чыгару турында уйламыйсызмы?**
  Китап бастырып чыгару бик зур чыгымнар сорый. Әлегә ул турыда уйлаганым юк. Авылымнан чыккан шагыйрәләрнең әсәрләрен туплап, “Заиковский” рәисе ярдәме белән “Күңел хатирәләре” җыентыгы дөнья күрде. Анда каләм тирбәтүчеләрнең шактый шигырьләре урын алды. Ул җыентыкта минем дә сигез шигырем бар. Сезнең игътибарга Минзәләнең юбилеена багышланган шигыремне тәкъдим итәсем килә.

***Матур булып кал син, Минзәләм!***

Һәркемнең дә бар бит туган көне
Җыелышып искә алалар.
Кешеләрдән кала бу бәйрәмне
Билгелиләр авыл, калалар.

Быел менә безнең Минзәләнең
Туган көне җитә, белегез.
Хезмәт сөйгән халкы белән бергә
Бәйрәм итәргә сез килегез!
Минзәләмнең яше арта бара,
Тик шәһәрем һаман яшәрә,
Шундый матур, гүзәл калабызда
Мөмкинлекләр арта яшәргә.
Зур-зур йортлар калкып чыга бүген,
Минзәләбез үсә, яңара.
Сөендереп, шушы гүзәллекне
Бизәп тора мәчет -манара.
Юл буенда тезелеп гөлләр үсә,
Яңаралар йортлар, урамнар.

Туган көнгә мондый матурлыктан
Кадерлерәк тагын нәрсә бар?
Шушы матурлыкны саклый белеп,
Гөлләр арасында яшәрбез.
Юбилейга, шәһәр бәйрәменә диеп
Төрле яктан дуслар дәшәрбез.
Туган көнең котлы булсын, шәһәр,
Җыелсыннар дуслар бәйрәмгә.
Минзәләбез белән горурланып
Язсын безгә, сөенеп яшәргә!
Матур булып кал син, яшьләргә!

*Сәхифәне Гарипова Нәргизә әзерләде*

# Гимназия сулышы



Бзнең гимназиягә мәркәзебездән килгән кунаклар – “Сабантуй” журналының баш мөхәррире Руфия Рифкат кызы Мөхетдинова һәм баш мөхәррир урынбасары Илсөяр Илгиз кызы Галиевалар кунакка килде. Бу килү очраклы гына түгел иде, чөнки безнең башлангыч сыйныф укучыларының барысы да “Сабантуй” һәм “Салават күпере” журналларына бик теләп язылдылар. Кунакларны милли киемнәрдән киенгән укучыларыбыз татар халкының милли ризыгы чәкчәк белән каршы алдылар. Һәм әти-әниләр ярдәме белән, башлангыч сыйныф укучылары көзге байлыкка багышлап, сый – хөрмәттән сыгылып торган табын әзерләделәр. Анда нинди генә нигъмәтләр юк иде: пирог, бәлеш, компот, кайнатма, как, желе һәм бик күп төрле камыр ризыклары. Шунысы куанычлы: һәр сыйныфтан укучылар матур итеп, саф татарча шигырен сөйләп, җырын җырлап, кунакларны каршы алды. Очрашу барышында кунакларыбыз да укучыларның белемнәрен сынап карарга өлгерделәр. Укучыларга мәкальләрне дәвам итү, табышмакларга җавап табу белән бергә, фразеологик берәмлекләрнең дә мәгънәсен аңлатырга туры килде. Укучылар сынатмады һәм биремнәрне бик тиз башкарып чыктылар. Кунаклар да буш кул белән килмәгәннәр. Балаларга “Сабантуй” журналы белән бергә истәлекле бүләкләр дә калдырып киттеләр.





***



Ел саен Татарстан Республикасының «Сәләт» хөкүмәте ярдәмендә 55 тән артык проект гамәлгә ашырыла, аларда 25000 дән артык сәләтле бала һәм барлык районнардан сәләтле яшьләр катнаша. "Ел клублар" номинациясе Татарстан Республикасы хөкүмәте ярдәмендә "Сәләт" яшьләр үзәге Дәүләт бюджет учреждениесе белән бер үк вакытта "Сәләт" Татарстан төбәк яшьләр фонды тарафыннан үткәрелә. Конкурс сәләтле балаларга һәм талантлы яшьләргә ярдәм итү өлкәсендә ел саен бирелә торган "Сәмрух" XI премиясе этапларының берсе булып тора. “Сәләт” клубларының системалы эшләрен оештыру өчен төбәк клублары өчен 22 семинар-киңәшмә уздырылды. Быелгы семинар 2025 елның 11 октябреннән 17 октябрենә кадәр "Йолдызлы" базасында клублар семинары кысаларында узды. Читтән торып эшләү этабы нәтиҗәләре буенча финалистлар ачыкланды. Гимназиянең “Сәләт-Минзәлә” клубының активистлары да бу семинарга чакырылучылар исемлегендә иде. Семинарда барлыгы 15 районнан җыелган “Сәләт” клубы әгъзалары катнашты. Семинар вакытында клублар арасында медиактивлык, бердәмлек, кургәзмә конкурс программалары һәм мастер-класслар үткәрелде. Төбәк “Сәләт”клублары өчен XXII гамәли уку-укыту семинары кысаларында узган “Күргәзмә” конкурсында җиңү яулап, “Сәләт-Минзәлә” клубы Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министрлыгы, “Сәләт” яшьләр иҗтимагый фонды һәм Сәләт яшьләр үзәгенең дипломы белән бүләкләнде. Котлыйбыз һәм киләчәктә тагын да зуррак уңышлар телибез!!!

***

Гимназиядә 4А сыйныф укучылары (сыйныф җитәкчесе Асылгәрәева Г.Х.) башлангыч сыйныф укучылары белән **Сөмбелэ бәйрәме** үткәрде. Бәйрәмгә Уңыш бабай, Убырлы, Юешбикә дә килде. Балалар җырладылар, биеделәр, уйнадылар, табышмакларга җавап таптылар. Бәйрәм бик кызык һәм матур үтте.



***

Әтиләр көне уңаеннан гимназиядә волейбол ярышы узды. Ярышта һәр сыйныфта укучы балаларның әтиләре бик теләп катнашты, ә әниләр аларга көч - куәт биреп тордылар. Килгән барлык әтиләргә, гаиләләргә рәхмәт белдерәбез.

Әтиебез бик гадел,<br>
Юмарт, шаян һәм көчле,<br>
Безнең өчен ул терәк,<br>
Әти безгә бик кирәк.

